**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

# Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы КАРАРЫ

**2017 елның «14» декабреннән** **№31-184**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-219 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

«Коррупциягә каршы тору турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы Указының 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-219 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«15.6. Әлеге Нигезләмәнең 15.1, 15.3 һәм 15.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының «д» пунктчасының икенче һәм абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан запрослар нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының һәм «д» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм белдерүләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивацияле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең яки башка карарның 20, 21, 22 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**